КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 март г.Казань № 298

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1032 нче; 2017 ел, 22 февраль, 113 нче; 2018 ел, 14 май, 354 нче; 2020 ел, 24 сентябрь, 863 нче; 2021 ел, 31 май, 422 нче; 2022 ел, 22 февраль, 151 нче, 2022 ел, 9 июль, 660 нчы, 2022 ел, 15 декабрь, 1339 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм

территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик заты капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

10 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) түгел.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин